КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 февраль г.Казань № 67

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1152 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1227 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2021 ел, 31 август, 791 нче; 2021 ел, 12 ноябрь, 1065 нче; 2022 ел, 18 гыйнвар, 22 нче; 2022 ел, 14 апрель, 355 нче; 2023 ел, 22 сентябрь, 1175 нче; 2024 ел, 26 апрель, 278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына, татар текстында 14 пунктның «ж» пунктчасындагы «шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру» сүзләрен «торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь,

962 нче; 2018 ел, 12 октябрь, 920 нче; 2021 ел, 26 май, 370 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче; 2024 ел, 12 сентябрь, 771 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә, 2 пунктның 6 пунктчасындагы «крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин